| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
09.09.2022

КАРАР
№ 998

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза үтәлә торган оешмалар исемлеген һәм мәҗбүри эш төрләрен билгеләү турында

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 32.13 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза билгеләнгән затларны Татарстан Республикасы буенча Федераль суд приставлары хезмәте идарәсе белән килештерү буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Административ җәза үтәү өчен мәҗбүри эш төрләрен 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза билгеләнгән затлар мәҗбүри эшләрне башкарган оешмалар исемлеген 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Күрсәтелгән административ җәза билгеләнгән затларның яшәү урыны буенча мәҗбүри эшләрне башкарырга.
4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәгән физик затларга эш терләрен, объектларны һәм урыннарны билгеләү турында» 2022 елның 17 июнендәге 283 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Хәмзин

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Нурлат
муниципаль районы Башкарма
комитетының 09.09.2022 № 998
карары белән расланды

**Административ җәза үтәү өчен мәҗбүри эш төрләре**

– Урамнарны, җәмәгать файдалануындагы территорияләрне җыештыру, яшелләндерү, йорт яны территорияләрен, ял зоналарын, паркларны, район һәм шәһәр скверларын чистарту һәм төзекләндерү;

– Тарихи-архитектура һәйкәлләрен, ял итү зоналарын, мәдәният паркларын торгызу һәм саклау, , чүп үләннәрен утау, газоннарны, чәчәклекләрне яшелләндерү, утырту, су сибү, үлән һәм коры-үләнне чабып тору;

– Үләннәрне йолку, агачларны һәм куакларны кисү, агарту, чүп үләннәрен җыештыру, җәмәгать файдалануындагы территорияләрдә коелган яфракларны җыештыру;

– Юл еслекләрен пычрактан, чүп-чардан һәм юл техникасы карны чистарта алмаган урыннарда җыештыру;

– Тротуарларны, тротуар плитәләрен, брусчаткаларны чистарту, урамнарны чистарту, билгеле бер квалификация таләп итмәгән тротуарлар һәм килеп туктау юлларын җыештырганда ярдәмче эшләр башкару;

– Иҗтимагый җәмәгать территорияләрендә кече архитектура формаларын буяу.

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы Нурлат
муниципаль районы Башкарма
комитетының 09.09.2022 № 998
карары белән расланды

**Мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтәү өчен объктлар исемлеге (килештерү буенча)**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты
2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары (килештерү буенча).
3. "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәсе компаниясе» муниципаль унитар предприятиесе.
4. "Нурлат өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат-йорты" дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе.